**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ НОВОКАДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
Советская ул, 51, с.Утыз Имян, 423109

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЯҢА КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 51, Утыз Имән авылы,423109

тел.(884396) 2-01-45 факс (884396) 2-01-45 email: Nkad.Cmn@tatar.ru

**№119** **«20» июнь 2024 ел**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Яңа Кади авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

**Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Төбәк салымнары суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге Уставы нигезендә КАРАР КЫЛДЫ:

1. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

3) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар һәм җыемнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

4) «Башкарма производство турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 һәм 47 статьяларының 1 өлешендәге 3,4

пунктларына ярашлы рәвештә башкарма производствоны тәмамлау турында суд приставы тарафыннан карар чыгару;

5) салым түләүче физик затның гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы (өлкәннәр, инвалидлар, яшь инвалидлар, инвалид балалар, сугыш һәм хезмәт ветераннары өчен интернат - йортларда; интернат-йортларда, шул исәптән психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар йортларында; махсус интернат-йортларда, шул исәптән картлар һәм башкалар өчен) җирле үзидарә органнары тәкъдим иткән документлар нигезендә;

6) ата-аналары ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән балалар йортларында һәм приютта тәрбияләнүче балигъ булмаган физик затлар;

7) җирле үзидарә органнарыныңраслаучы документлары булган очракта аз керемле физик затлар;

8) психик тайпылышлары булган, суд карары яки җирле үзидарә органнары тәкъдим иткән документлар нигезендә суд тәртибендә эшкә сәләтсез дип танылган физик затлар;

9) ирегеннән мәхрүм итү урыннарында булган физик затлар, - суд карары нигезендә иректән мәхрүм итү урыннарында булу чорына.

10) физик затларда Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

ТР Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 2023 елның 29 маендагы № 85 карары (җирлек Советының 2023 елның 18 октябрендәге 98 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Яңа Кади авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе: М.М.Әминов